# Ант итү

## احكام اليمين

اللغة التترية

Шәйх Хәйсәм ибн Мөхәммәд
Сәрхән

ALSARHAAN.COM

اليمين ، القسم :
وهي في الشرع توكيد شيء بذكر معظم على وجه مخصوص

**Шаригатьтә ант итү – ул синең өчен бөек булган нәрсәләрне кулланып нидер раслау я инде хаклау.**

وصيغة اليمين تكون بذكر اسم الله تعالى مثل والله والرحمن او بصفة له مثل وعزة الله وجلاله

**Ант яки Аллаһ исемнәрен, яки Аллаһның сыйфатларын кулланылып әйтелә. Мәсәлән: "Аллаһ белән ант итәм", "Рәхим-шәфкать Иясе Аллаһ белән ант итәм", "Аллаһның бөеклеге белән ант итәм".**

والحكمة من اليمين التأكيد.

**Ант итүнең хикмәте – ул да булса нәрсәнедер исбат итү.**

وهو إما لحمل المخاطب على الثقة بكلام الحالف.
وإما لتقوية عزم الحال في نفسه على فعل شيء.
أو ترك شيء وإما لتقوية الطلب من المخاطب أو غيره.
وحثه على فعل شيء أو منعه عنه ،

Кешеләр кайвакыт ниндидер сүзнең хаклыгын көчәйтер өчен, шулай ук нидер эшләргә, я инде киресенчә нидер калдырырга үз-үзләренә көч бирер өчен, кайвакыт сөйләүченең хәбәрен раслау өчен һәм шулай ук берәр кешене нидер эшләргә чакыру, я инде нидәндер тыю өчен ант сүзләрен кулланалар.

ويكره الإكثار من الإيمان

Ләкин кирәктән тыш күп итеп ант итү кирәкмәгән гамәл булып исәпләнә.

قال تعالى : ولا تطع كل حلاف مهين.

Аллаһ Раббыбыз әйтте: "Һәм һәрбер күп итеп ант итүче түбән кешегә буйсынма".

أي كثير الحلف بالحق والباطل.
Ягъни хаклыкка да ялганга да күп итеп ант итүчегә.
Хаклык белән дә ялган белән дә.

وقال تعالى : واحفظوا أيمانكم.
Шулай ук Раббыбыз: "Антыгызны саклагыз",- диде.

ولا يجوز الحلف إلا بالله تعالى.
قال رسول صلى الله عليه وسلم:  إن الله ينهاكم أن تحلفوا بآبائكم فمن كان حالفا فليحلف بالله وإلا فليصمت.
Шулай ук Аллаһтан кала беркем белән дә ант итәргә ярамый.
Аллаһның илчесе ﷺ әйтте:
"Чынлыкта Аллаһ әтиләрегез белән ант итүне тыйды. Кем дә кем ант итә икән, ул бары тик Аллаһ белән генә ант итсен, я инде дәшмәсен".

واليمين على أقسام
Ант итү берничә төргә бүленә:

منها اليمين المؤكِدة لخبر سابق.

Шулардан – булган хәлнең дөреслеген хаклау.

فإن كانت مطابقة للواقع فهي اليمين الصادقة.

Әгәр анты белән чыннан да хаклыкны раслый икән – бу дөрес ант була.

وان كان الحالف بها كاذبًا لإبطال حق أو احقاق باطل فهي اليمين الغموس لأنها تغمس صاحبها في الإثم إلا أن يتوب ويرد الحقوق.

Әгәр дөреслекне ялганга чыгару, яисә ялганны хаклар өчен ант итә икән – бу ялган ант була. Ялган ант иткән кеше тәүбәгә килеп, золымлык кылган кешесенә хакларын кайтарып бирми икән үзенә зур гөнаh ала.

ومنها اليمين المؤكدة لإنشاء أمر في المستقبل.

Шулай ук ант итүнең төрләреннән – киләчәктә нидер эшләр өчен ант итү.

وهي للحث أو ليحمل الحالف بها نفسه أو غيره على فعل شيء أو ترك شيء في المستقبل.

Мондый ант белән ант итүче киләчәктә нидер эшләргә я инде нидер калдырырга үзен йөкли.

كأن يقول: والله لأذهبن إلى فلان أو والله لا أدخل بيت فلان.

Мәсәлән: "Аллаһ белән ант итәм, мин фәлән кеше янына барачакмын", я инде: "Аллаһ белән ант итәм, мин фәлән кешенең өенә кермәячәкмен", - дигән сүзләр.

وهذه اليمين تسمى منعقدة او معقودة متى تمت شرائطها.

Әгәр барлык шартлары да туры килә икән, мондый ант сүз бирү анты дип атала.

ومنها اليمين غير المؤكدة وإنما هي من لغو اللسان.
وهي التي يلفظها بلا قصد لمعناها.
كقول لا والله وبلى والله وهذه يمين غير منعقدة.

Шулай ук ант итү төрләреннән – бер максатсыз, бары тик сүз өчен генә ант итү. Мондый антны ант итүче бу антын нидер раслау өчен түгел, ә бары тик сүз бәйләнеше өчен куллана.

ومن حلف على يمين فرأى غيرها خيرا منها فليأت الذي هو خير. وليكفر عن يمينه.

Әгәр берәр кеше, нидер әшлим дип сүз бирү анты белән ант итә икән, шушы гамәлен эшләргә вакыт килеп җиткәч, бу гамәлдән хәерлерәк гамәл күрә икән, бу ант итеп сүз биргән гамәлен калдырып хәерләрәк гамәлне эшләргә тиеш.

والكفارة لا تكون إلا في اليمين المنعقدة.
وهي كما في قوله تعالى :لا يؤاخذكم الله باللغو في
أيمانكم ، ولكن يؤاخذكم بما عقدتم الأيمان.
فكفارته إطعام عشرة مساكين من أوسط ما تطعمون
أهليكم أو كسوتهم أو تحرير رقبة.
فمن لم يجد فصيام ثلاثة أيام.
ذلك كفارة أيمانكم إذا حلفتم

Ләкин ул бу антын бозганы өчен, Аллаһ Коръәндә әйткәнчә, ант бозу җәзасын үтәргә тиеш.
Аллаһ Раббыбыз әйтте:
"Аллаһ сездән болай гына әйткән антыгыз өчен сорамаячак, әмма дә ләкин сүз биру антыгыз өчен сораячак. (Әгәр сез сүз бирү анты белән ант итеп бу антыгызны үтәмәсәгез) моның җәзасы – якынча үзегезнең гаиләгезне ашаткан ризык белән ун мескенне ашату, я инде киендерү, я инде бер колны азат итү. Кем боларны эшли алмаса, өч көн ураза тотсын. Һәм болар барысы да сүз бирү антын бозуның гөнаһыннан чистарыну була.

فبينت الآية الكريمة أن كفارة اليمين المعقودة واجبة على التخيير ابتداء والترتيب انتهاء.
فالحالف اذا حنث في يمينه وجب عليه إحدى خصال ثلاث على التخيير.
اطعام عشرة مساكين أو كسوتهم او تحرير رقبة.
فاذا عجز عن الثلاث وجب عليه صيام ثلاثة أيام.
والأفضل أن تكون متتابعة.

**Шулай итеп, сүз бирү антын бирүче антын боза икән, бу аятьтә килгән өч нәрсәнең берсен сайларга тиеш: я инде мескеннәрне ашату, я инде мескеннәрне киендерү, я инде колны азат итү. Сайлаганда санап үткән тәртипкә өстенлек бирә. Әгәр бу өч нәрсәнең берсен дә эшләргә мөмкинлеге юк икән, өч көн ураза тота.**

ومن استثنى في يمينه فقال: افعلُ والله إن شاء الله
أو لا أفعل والله إن شاء الله
فهذا لا تلزمه الكفارة.

Берәр нәрсә эшлим, я инде эшләмим дип ант итүче ант иткәндә "Ин шәә Аллаһ" дип әйтә икән, антын бозган очракта да аңа җәза юк.

قال رسول الله صلى الله عليه وسلم : من حلف على يمين فقال : ان شاء الله فقد استثنى فلا حِنْثَ عليه

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Кем дә кем ант иткәндә " Ин шәә Аллаһ" дип әйтә икән, бу кешегә җәза юк."